| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**КУЛЕГАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**<br>**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**КҮЛӘГӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2021 Күләгәш авылы № 16

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агач, куаклар кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 02 сентябрендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агач, куаклар кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 02 сентябрендәге 15 номерлы карары белән расланган агач, куаклар кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның авария хәлендә булуы турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның Башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 подпунктларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү яисә Башкарма комитет нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «Муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә бик кирәк булган очракта (авария хәлендәге агачлар) яшел үсентеләрне бетерү кирәклеген раслау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкаруга яисә яшел утыртмаларны җимерүгә бәйле очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру яисә яшел утыртмаларны бетерү өчен (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пуктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында «; авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә яшел утыртмаларны бетергәндә муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) - ике эш көнен төшереп калдырырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентка 2 нче кушымтада «Авария агачлары кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында элеп игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Җитәкчесе Ю.Н. Васильев